**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 31 декабрь № 1044

г. Казань

Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $69^2$ статьясындагы 3 нче һәм 4 нче пунктлар, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның $9^2$ статьясындагы 7 нче пунктның 2 нче пунктчасы һәм «Автоном учреждениеләр турында» 2006 ел, 3 ноябрь, ФЗ-174 нче Федераль законның 4 статьясындагы 5 өлешнең 2 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү турындагы нигезләмәне (алга таба – дәүләт йөкләмәсе, Нигезләмә) расларга.

2. Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарына үз ведомстволарына караган дәүләт учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләрен күрсәтүне (эшләр башкаруны) бары тик расланган дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәләре нигезендә генә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Җирле үзидарә органнарына 2017 елның 1 гыйнварыннан муниципаль учреждениеләргә карата муниципаль йөкләмә формалаштыру һәм муниципаль йөкләмәне финанслар белән тәэмин итү тәртибен билгеләү буенча шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары белән берлектә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән әлеге чыгымнарны билгеләү тәртипләре нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә, эшләр башкаруга норматив чыгымнар күләмнәрен ел саен хисаплауны һәм Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертүне тәэмин итәргә.

5. Алар өчен әлеге карарның гамәле 2017 елның 1 гыйнварыннан керә торган белем бирү оешмаларыннан, мәдәният, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләреннән тыш, Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган мөлкәт базасында төзелгән дәүләт бюджет оешмалары һәм автоном оешмалар өчен бу карарның гамәле 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

6. 2017 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 28 октябрь, 859 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 30 март, 240 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 9 февраль, 94 нче.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

**РАСЛЫЙМ**

Җитәкче
(вәкаләтле зат)

______________________________________________

(дәүләт бюджет учреждениесен яки автоном учреждениене гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы орган, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче исеме)

_________________ _________ _______________

(вазыйфасы) (имзасы) (имзаның аңлатмасы)

"______" _________________________ 20__ ел

20 ____ елга, 20 ____ һәм 20 ____ еллар план чорына

__________ **ДӘҮЛӘТ ЙӨКЛӘМӘСЕ** <1>

| Дәүләт учреждениесе исеме: | | Кодлар |
|---|---|---|
| | ОКУД буенча форма | 0506001 |
| ______________________________ | | |
| ______________________________ | Җыелма реестр буенча | |
| Дәүләт учреждениесенең эшчәнлек төрләре: | | |
| ______________________________ | дата | |
| ______________________________ | ОКВЭД буенча | |

_____________________________________________ ОКВЭД буенча
_____________________________________________ ОКВЭД буенча
Дәүләт учреждениесе төре: ______________________________
(ведомстволар исемлегеннән дәүләт учреждениесе төре күрсәтелә)

1 өлеш. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре турында мәгълүматлар <2>
______ бүлек

1. Дәүләт хезмәте исеме: ______________________________ Ведомстволар
______________________________ исемлеге буенча
______________________________ уникаль
2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучыларның категорияләре: ______________ саны
______________________________

3. Дәүләт хезмәтенең күләмен һәм (яки) сыйфатын тасвирлый торган күрсәткечләр
3.1. Дәүләт хезмәтенең сыйфатын тасвирлый торган күрсәткечләр <3>:

| Реестр язуы уникаль саны | Дәүләт хезмәтенең эчтәлеген тасвирлый торган күрсәткеч | | | Дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын (формаларын) тасвирлый торган күрсәткеч | | Дәүләт хезмәте сыйфаты күрсәткече | | | Дәүләт хезмәте сыйфаты күрсәткеченең мәгънәсе | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | күрсәт-кеч исеме | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | 20__ ел (чираттагы финанс елы) | 20__ ел (план чорының 1 нче елы) | 20__ ел (план чорының 2 нче елы) |
| | _______ (күрсәткеч исеме) | _______ (күрсәткеч исеме) | _______ (күрсәткеч исеме) | _______ (күрсәткеч исеме) | _______ (күрсәткеч исеме) | | исеме | коды | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | | | | |

Аларның чикләрендә дәүләт йөкләмәсе үтәлгән дип санала торган дәүләт хезмәте сыйфатының билгеләнгән күрсәткечләреннән рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышлар (процент) ________________________

3.2. Дәүләт хезмәтенең күләмен тасвирлый торган күрсәткечләр:

| Реестр язуы уникаль саны | Дәүләт хезмәтенең эчтәлеген тасвирлый торган күрсәткеч | | | Дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын (формаларын) тасвирлый торган күрсәткеч | | Дәүләт хезмәте күләме күрсәткече | | | | Дәүләт хезмәте күләме күрсәткече мәгънәсе | | | Уртача еллык түләү күләме (бәя, тариф) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | _________ (күрсәткеч исеме) | _________ (күрсәткеч исеме) | _________ (күрсәт-кеч исеме) | _________ (күрсәткеч исеме) | _________ (күрсәткеч исеме) | күр-сәткеч исеме | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | хез-мәт-нең тас-вир-лама-сы <4> | 20__ ел (чират-тагы финанс елы) | 20__ ел (план чоры-ның 1 нче елы) | 20__ ел (план чоры-ның 2 нче елы) | 20__ ел (чират-тагы финанс елы) | 20__ ел (план чоры-ның 1 нче елы) | 20__ ел (план чоры-ның 2 нче елы) |
| | | | | | | | исе-ме | ко-ды | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | |

Аларның чикләрендә дәүләт йөкләмәсе үтәлгән дип санала торган дәүләт хезмәте күләменең билгеләнгән күрсәткечләреннән рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышлар (процент) ____________________

4. Түләү күләмен (бәяне, тарифны) яки аны билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актлар:

| Норматив хокукый акт | | | | |
|---|---|---|---|---|
| төре | кабул иткән орган | дата | саны | исеме |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар:

__________________________________________________________________

(төре, датасы, норматив хокукый акт саны)

5.2. Дәүләт хезмәтеннән потенциаль файдаланучыларга мәгълүмат бирү тәртибе:

| Мәгълүмат бирү ысулы | Урнаштырыла торган мәгълүмат составы | Мәгълүматны яңарту ешлыгы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |
| | | |

2 өлеш. Башкарыла торган эшләр турында мәгълүматлар <5>
_____ бүлек

1. Эшнең исеме: ________________________________________________________________ Ведомстволар исемлеге буенча уникаль саны
________________________________________________________________
________________________________________________________________
2. Эштән файдаланучылар категорияләре: ________________________________________
________________________________________________________________

3. Эшнең күләмен һәм (яки) сыйфатын тасвирлый торган күрсәткечләр
3.1. Эшнең сыйфатын тасвирлый торган күрсәткечләр <6>:

| Реестр язуы уникаль саны | Эшнең эчтәлеген тасвирлый торган күрсәткеч (белешмәлекләр буенча) | | | Эшне башкару шартларын (формаларын) тасвирлый торган күрсәткеч (белешмәлекләр буенча) | | Эшнең сыйфаты күрсәткече | | | Эшнең сыйфаты күрсәткече мәгънәсе | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | күрсәт-кеч исеме | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | 20__ ел (чираттагы финанс елы) | 20__ ел (план чорының 1 нче елы) | 20__ ел (план чорының 2 нче елы) |
| | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | | исеме | коды | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Аларның чикләрендә дәүләт йөкләмәсе үтәлгән дип санала торган эш сыйфатының билгеләнгән күрсәткечләреннән рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышлар (процент) ________________

3.2. Эшнең күләмен тасвирлый торган күрсәткечләр:

| Реестр язуы уникаль саны | Эшнең эчтәлеген тасвирлый торган күрсәткеч (белешмәлекләр буенча) | | | Эшне башкару шартларын (формаларын) тасвирлый торган күрсәткеч (белешмәлекләр буенча) | | Эшнең күләме күрсәткече | | | | Эшнең күләме күрсәткече мәгънәсе | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | күрсәткеч исеме | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | эшнең тасвирламасы <4> | 20__ ел (чираттагы финанс елы) | 20__ ел (план чорының 1 нче елы) | 20__ ел (план чорының 2 нче елы) |
| | | | | | | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |

Аларның чикләрендә дәүләт йөкләмәсе үтәлгән дип санала торган эш күләменең билгеләнгән күрсәткечләреннән рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышлар (процент) __________________

3 өлеш. Дәүләт йөкләмәсе турында башка мәгълүматлар <7>

1. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне вакытыннан алда туктату өчен нигезләр

2. Дәүләт йөкләмәсен үтәү (үтәүне контрольдә тоту) өчен кирәкле башка мәгълүмат

3. Дәүләт йөкләмәсен үтәүгә контроль тоту тәртибе

| Контроль формасы | Кабатлану вакыты | Дәүләт йөкләмәсен үтәүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |
| | | |

4. Дәүләт йөкләмәсен үтәү турындагы хисаплылыкка таләпләр
4.1. Дәүләт йөкләмәсен үтәү турында хисаплар кертүнең кабатлану вакыты:

4.2. Дәүләт йөкләмәсен үтәү турындагы хисапларны кертү вакытлары:

4.3. Дәүләт йөкләмәсен үтәү турындагы хисаплылыкка башка таләпләр:

5. Дәүләт йөкләмәсен үтәүгә бәйле башка күрсәткечләр <8>:

<1> Дәүләт йөкләмәсе саны Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне планлаштыру һәм мониторинглау буенча бердәм ведомствоара мәгълүмати ресурс

формалаштыру системасында бирелә.

<2> Дәүләт хезмәте (хезмәтләре) күрсәтүгә һәм эш (эшләр) башкаруга дәүләт йөкләмәсен билгеләгәндә формалаштырыла һәм, бүлекнең тәртип санын күрсәтеп, дәүләт хезмәтләренең һәрберсе буенча аерым дәүләт хезмәте (хезмәтләре) күрсәтүгә таләпләрне үз эченә ала.

<3> Дәүләт хезмәтләре һәм эшләрнең ведомстволар исемлегендә дәүләт хезмәте сыйфатын тасвирлый торган күрсәткечләрне билгеләгәндә тутырыла.

<4> Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеге составында хезмәтнең (эшнең) тасвирламалары булганда тутырыла.

<5> Дәүләт хезмәте (хезмәтләре) күрсәтүгә һәм эш (эшләр) башкаруга дәүләт йөкләмәсен билгеләгәндә формалаштырыла һәм, бүлекнең тәртип санын күрсәтеп, эшләрнең һәрберсе буенча аерым эш (эшләр) башкаруга таләпләрне үз эченә ала.

<6> Дәүләт хезмәтләре һәм эшләрнең ведомстволар исемлегендә эшнең сыйфатын тасвирлый торган күрсәткечләрне билгеләгәндә тутырыла.

<7> Дәүләт йөкләмәсе буенча гомумән алганда тутырыла.

<8> Дәүләт бюджет учреждениеләрен яки автоном учреждениеләрне гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы орган, карамагында казна учреждениеләре булган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче тарафыннан аның чикләрендә дәүләт йөкләмәсе үтәлгән дип санала торган дәүләт йөкләмәсе үтәлешеннән рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышларны (процентларда) билгеләү турында карар кабул ителгәндә, башка күрсәткечләр арасында аның чикләрендә дәүләт йөкләмәсе үтәлгән дип санала торган дәүләт йөкләмәсен үтәлешеннән рөхсәт ителгән (мөмкин булган) гомуми тайпылыш күрсәтелгән булырга мөмкин. Бу очракта әлеге дәүләт йөкләмәсенең 3 нче пунктындагы 3.1 һәм 3.2 нче пунктчаларда каралган рөхсәт ителгән (мөмкин булган) күрсәткечләр тутырылмый.

---

Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

20 ____ елга, 20 ____ һәм 20 ____ еллар план чорына

**_______ ДӘҮЛӘТ ЙӨКЛӘМӘСЕН ҮТӘҮ**

**ТУРЫНДА ХИСАП** <1>

20__ ел, «__» ____________

| | | Кодлар |
|---|---|---|
| Дәүләт учреждениесе исеме: | ОКУД | 0506001 |
| ______________________________ | буенча форма | |
| ______________________________ | Җыелма | |
| Дәүләт учреждениесенең эшчәнлек төрләре: | реестр буенча | |
| ______________________________ | дата | |
| ______________________________ | ОКВЭД буенча | |
| ______________________________ | ОКВЭД буенча | |
| ______________________________ | ОКВЭД буенча | |
| Дәүләт учреждениесе төре: ______________________ | | |

(ведомстволар исемлегеннән дәүләт учреждениесе төре күрсәтелә)

Кабатлану вакыты ______________________________

(дәүләт йөкләмәсендә билгеләнгән дәүләт йөкләмәсен үтәү турында хисап кертүнең кабатлану вакыты нигезендә күрсәтелә)

1 өлеш. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре турында мәгълүматлар <2>

_____ бүлек

1. Дәүләт хезмәте исеме ________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________

Ведомстволар исемлеге буенча уникаль саны

2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучыларның категорияләре _______________________
________________________________________________________________

3. Дәүләт хезмәтенең күләмен һәм (яки) сыйфатын тасвирлый торган күрсәткечләргә фактта ирешү турында мәгълүматлар
3.1. Дәүләт хезмәтенең сыйфатын тасвирлый торган күрсәткечләргә фактта ирешү турында мәгълүматлар:

| Реестр язуы уникаль саны | Дәүләт хезмәтенең эчтәлеген тасвирлый торган күрсәткеч | | | Дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын (формаларын) тасвирлый торган күрсәткеч | | Дәүләт хезмәте сыйфатының күрсәткече | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | күрсәткеч исеме | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | дәүләт йөкләмәсендә бер елга расланды | хисап датасына үтәлде | рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылыш | рөхсәт ителгән (мөмкин булган) мәгънәдән арткан тайпылыш | тайпылышның сәбәбе |
| | | | | | | | исеме | коды | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |

3.2. Дәүләт хезмәтенең күләмен тасвирлый торган күрсәткечләргә фактта ирешү турында мәгълүматлар:

| Реестр язуы уникаль саны | Дәүләт хезмәтенең эчтәлеген тасвирлый торган күрсәткеч | | | Дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын (формаларын) тасвирлый торган күрсәткеч | | Дәүләт хезмәте күләме күрсәткече | | | | | | | | Уртача түләү күләме (бәя, тариф) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | күрсәткеч исеме | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | дәүләт йөкләмәсендә бер елга расланды | хисап датасына үтәлде | рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылыш | рөхсәт ителгән (мөмкин булган) мәгънәдән арткан тайпылыш | тайпылышның сәбәбе | |
| | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | | исеме | коды | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | |

2 өлеш. Башкарыла торган эшләр турында мәгълүматлар <3>
_____ бүлек

1. Эшнең исеме: ______________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________
2. Эштән файдаланучылар категорияләре:___________ ____________________________________
_____________________________________________________________________________________

Ведомстволар исемлеге буенча уникаль саны

3. Эшнең күләмен һәм (яки) сыйфатын тасвирлый торган күрсәткечләргә фактта ирешү турында мәгълүматлар
3.1. Эшнең сыйфатын тасвирлый торган күрсәткечләргә фактта ирешү турында мәгълүматлар:

| Реестр язуы уникаль саны | Эшнең эчтәлеген тасвирлый торган күрсәткеч | | | Эш башкару шартларын (формаларын) тасвирлый торган күрсәткеч | | Эшнең сыйфаты күрсәткече | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | күрсәткеч исеме | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | дәүләт йөкләмәсендә бер елга расланды | хисап датасына үтәлде | рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылыш | рөхсәт ителгән (мөмкин булган) мәгънәдән арткан тайпылыш | тайпылышның сәбәбе |
| | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | ________ (күрсәткеч исеме) | | исеме | коды | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |

3.2. Эшнең күләмен тасвирлый торган күрсәткечләргә фактта ирешү турында мәгълүматлар:

| Реестр язуы уникаль саны | Эшнең эчтәлеген тасвирлый торган күрсәткеч | | | Эш башкару шартларын (формаларын) тасвирлый торган күрсәткеч | | Эшнең күләме күрсәткече | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | күрсәткеч исеме | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | дәүләт йөкләмәсендә бер елга расланды | хисап датасына үтәлде | рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылыш | рөхсәт ителгән (мөмкин булган) мәгънәдән арткан тайпылыш | тайпылышның сәбәбе |
| | ______ (күрсәткеч исеме) | ______ (күрсәткеч исеме) | ______ (күрсәткеч исеме) | ______ (күрсәткеч исеме) | ______ (күрсәткеч исеме) | | исеме | коды | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче (вәкаләтле зат) _____________ ___________ ______________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаның анлатмасы)

"__" __________ 20__ ел.

-------------------------------

<1> Дәүләт йөкләмәсе саны Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне планлаштыру һәм мониторинглау буенча бердәм ведомствоара мәгълүмати ресурс формалаштыру системасында бирелә.

<2> Дәүләт хезмәте (хезмәтләре) күрсәтүгә һәм эш (эшләр) башкаруга дәүләт йөкләмәсен билгеләгәндә формалаштырыла һәм, бүлекнең тәртип санын күрсәтеп, дәүләт хезмәтләренең һәрберсе буенча аерым дәүләт хезмәте (хезмәтләре) күрсәтүгә таләпләрне үз эченә ала.

<3> Дәүләт хезмәте (хезмәтләре) күрсәтүгә һәм эш (эшләр) башкаруга дәүләт йөкләмәсен билгеләгәндә формалаштырыла һәм, бүлекнең тәртип санын күрсәтеп, эшләрнең һәрберсе буенча аерым эш (эшләр) башкаруга таләпләрне үз эченә ала.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче
карары белән расланды

Дәүләт учреждениеләренә карата
дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру
һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү турында
нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган мөлкәт базасында төзелгән дәүләт бюджет учреждениеләре, автоном учреждениеләр (алга таба – автоном учреждениеләр), шулай ук карамагында дәүләт казна учреждениеләре булган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләрнең хокукый актлары белән билгеләнгән дәүләт казна учреждениеләре (алга таба – казна учреждениеләре) тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен (алга таба – дәүләт йөкләмәсе) формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибен билгели.

## I. Дәүләт йөкләмәсен формалаштыру (үзгәртү)

2. Дәүләт йөкләмәсе дәүләт учреждениесенең гамәлгә кую документлары белән күздә тотылган төп эшчәнлек төрләре нигезендә, хезмәтләр һәм эшләрдән файдаланучылар санының фаразлана торган динамикасы нигезендә бәяләнә торган тиешле хезмәтләрдә һәм эшләрдә ихтыяҗга, гамәлдәге хезмәтләр күрсәтү күләме һәм сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсенә һәм хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару буенча дәүләт учреждениесенең эш нәтиҗәләренә һәм мөмкинлекләренә, шулай ук хисап финанс елында дәүләт учреждениесенең дәүләт йөкләмәсен үтәү күрсәткечләренә кагылышлы булган дәүләт учреждениесе тәкъдимнәрен исәпкә алып формалаштырыла.

3. Дәүләт йөкләмәсе үз эченә дәүләт хезмәте (эш) сыйфатын һәм (яки) күләмен (эчтәлеген) тасвирлый торган күрсәткечләрне, тиешле хезмәтләрдән файдаланучы булган физик һәм (яки) юридик затларның категорияләрен билгеләүне, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнарында хезмәтләрне түләүле нигездә күрсәтү күздә тотылган очракларда, физик яки юридик затлар тарафыннан тиешле хезмәтләр өчен түләүгә иң чик бәяләрне (тарифларны) яисә Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән очракларда, әлеге бәяләрне (тарифларны) билгеләү тәртибен, дәүләт йөкләмәсе үтәлешен тикшерүдә тоту тәртибен, дәүләт йөкләмәсен үтәү турындагы хисаплылыкка таләпләрне ала.

Дәүләт йөкләмәсе әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча формалаштырыла.

Дәүләт учреждениесенә берничә дәүләт хезмәте күрсәтүгә (берничә эш

башкаруга) дәүләт йөкләмәсен билгеләгәндә, дәүләт йөкләмәсе һәрберсе бер дәүләт хезмәте күрсәтүгә (бер эш башкаруга) таләпләрне үз эченә алырга тиешле берничә өлештән формалаштырыла.

Дәүләт учреждениесенә дәүләт хезмәте (хезмәтләре) күрсәтүгә һәм эш (эшләр) башкаруга дәүләт йөкләмәсен билгеләгәндә, дәүләт йөкләмәсе һәрберсе аерым дәүләт хезмәте (хезмәтләре) күрсәтүгә һәм эш (эшләр) башкаруга таләпләрне үз эченә алырга тиешле ике өлештән формалаштырыла. Дәүләт йөкләмәсенә гомумән алганда кагылышлы мәгълүмат дәүләт йөкләмәсенең өченче өлешенә кертелә.

4. Дәүләт серен һәм федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары нигезендә саклана торган башка серне (алга таба – дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар) тәшкил иткән мәгълүматларны үз эченә алмаган дәүләт йөкләмәсе һәм дәүләт йөкләмәсен үтәү турындагы хисап Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне планлаштыру һәм мониторинглау буенча бердәм ведомствоара мәгълүмати ресурс формалаштыру системасында электрон рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә формалаштырыла һәм карамагында казна учреждениесе булган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче яисә дәүләт бюджет учреждениесен яки автоном учреждениене гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы (алга таба – дәүләт бюджет учреждениесен яки автоном учреждениене гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы орган) исеменнән эш итү хокукына ия затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларны үз эченә алган дәүләт йөкләмәсе, дәүләт сере турындагы Россия Федерациясе законнарын үтәп, кәгазь документ рәвешендә формалаштырыла.

5. Дәүләт йөкләмәсе чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыру процессында формалаштырыла һәм түбәндәгеләргә карата дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү өчен субсидия (алга таба – субсидия) бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче раслаган көннән 15 эш көненнән дә соңга калмыйча расслана:

а) казна учреждениеләренә карата – карамагында казна учреждениесе булган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче тарафыннан;

б) бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләргә карата – дәүләт бюджет учреждениесен яки автоном учреждениене гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы орган тарафыннан.

6. Дәүләт йөкләмәсе Татарстан Республикасы бюджет законнарында билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыру вакытына туры килгән вакытка билгеләнә.

Дәүләт йөкләмәсе күрсәткечләренә үзгәрешләр керткән очракта, әлеге бүлек нигезләмәләре нигезендә яңа дәүләт йөкләмәсе формалаштырыла (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

7. Дәүләт йөкләмәсе билгеләнгән эшчәнлек өлкәләрендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу вазыйфаларын башкаручы федераль башкарма хакимият органнары раслаган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең һәм эшләрнең төп (тармак) исемлекләре (алга таба – төп (тармак) исемлек) нигезендә формалаштырылган, карамагында казна учреждениесе булган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче яисә дәүләт бюджет учреждениесен яки автоном учреждениене гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы орган раслаган дәүләт учреждениеләре тарафыннан төп эшчәнлек төрләре буларак күрсәтелә (башкарыла) торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләрнең ведомстволар исемлеге (алга таба – ведомстволар исемлеге) нигезендә формалаштырыла.

8. Дәүләт йөкләмәләре һәм дәүләт йөкләмәләрен үтәү турында хисаплар, алар үз эченә алган дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлардан тыш, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначалык департаменты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру буенча рәсми сайтта (www.bus.gov.ru) урнаштырыла, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге карамагында казна учреждениесе булган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләрнең һәм дәүләт бюджет учреждениесен яки автоном учреждениене гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы органнарның рәсми сайтларында урнаштырыла ала.

## II. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү

9. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү күләме дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар, эшләр башкаруга бәйле норматив чыгымнар нигезендә, дәүләт учреждениесенә беркетелгән яки аңа гамәлгә куючы тарафыннан әлеге мөлкәтне сатып алуга бүленеп бирелгән акча исәбеннән сатып алынган күчемсез мөлкәтне һәм аеруча кыйммәткә ия мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләрен (арендага яки түләүсез файдалануга бирелгән мөлкәттән тыш) (алга таба – учреждение мөлкәте) тотуга чыгымнарны, алар буенча учреждение мөлкәте салым салу объекты дип танылган салымнарны түләүгә чыгымнарны исәпкә алып исәпләнә.

10. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү күләме (R) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R = \sum_i N_i \times V_i + \sum_w N_w - \sum_i P_i \times V_i \quad + N_{ун}\,,$$

монда:

$N_i$– ведомстволар исемлегенә кертелгән i дәүләт хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар;

$V_i$ – дәүләт йөкләмәсе белән билгеләнгән i дәүләт хезмәте күләме;

$N_w$ – ведомстволар исемлегенә кертелгән w эшне башкаруга норматив чыгымнар;

$P_i$ – дәүләт йөкләмәсе белән билгеләнгән, әлеге Нигезләмәнең 28 нче пункты нигезендә i дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түләү күләме (тариф, бәя);

$N_{ун}$ – алар буенча учреждение мөлкәте салым салу объекты дип танылган салымнарны түләүгә чыгымнар.

11. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар әлеге Нигезләмә буенча билгеләнә торган чыгымнарның база нормативы һәм чыгымнарның база нормативына коррекцияләү коэффициентлары (алга таба – коррекцияләү коэффициентлары) нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән берлектә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан эшләнә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган учреждениеләрнең хезмәтләр күрсәтүгә һәм эшләр башкаруга норматив чыгымнарын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәләрне (алга таба – норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе турында нигезләмәләр) үтәп, дәүләт йөкләмәсендә билгеләнгән хезмәт күрсәтү күләме күрсәткече берәмлегенә исәпләнә.

12. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар түбәндәге база норматив чыгымнардан тора:

а) дәүләт хезмәте күрсәтүгә турыдан-туры бәйле чыгымнар;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гомумхуҗалык ихтыяҗларына чыгымнар.

13. База норматив чыгымнар, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты күрсәткечләрен, шулай ук база (тармак) исемлектә билгеләнгән, алар булганда тармак коррекцияләүче коэффициентның мәгънәсе 1гә тигез дәүләт хезмәтенең тармак үзенчәлеген (дәүләт хезмәтенең эчтәлеге, аны күрсәтү шартлары (формалары)) чагылдыра торган күрсәткечләрне (алга таба – тармак үзенчәлеге күрсәткечләре) саклап, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле чыгымнардан чыгып исәпләнә.

14. База норматив чыгымнарны билгеләгәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, шулай ук Россия Федерациясе дәүләтара, милли (дәүләт) стандартлары, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, санитария нормалары һәм кагыйдәләре, билгеләнгән өлкәдә дәүләт хезмәтләре күрсәтү стандартлары, тәртипләре һәм регламентлары (алга таба – хезмәт стандартлары) белән билгеләнгән, дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен файдаланыла торган матди, техник ресурслар һәм хезмәт ресурслары нормалары кулланыла.

15. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә турыдан-туры бәйле база норматив чыгымнарга түбәндәгеләр керә:

а) хезмәт өчен түләүгә чыгымнар, шул исәптән хезмәт стандарты белән билгеләнгән очракларда административ-идарә итү персоналын кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтүгә турыдан-туры бәйле хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү буенча акча күчерүләр, хезмәт турында законнар һәм хезмәт хокукын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә иминият кертемнәрен исәпкә алып (алга таба – хезмәт өчен түләүгә акча күчерү);

б) нәтиҗәле файдалану вакытын исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү процессында кулланыла (файдаланыла) торган матди запаслар һәм аеруча кыйммәткә ия күчемле мөлкәт сатып алуга чыгымнар (шул исәптән аренда түләүләренә чыгымнар);

в) дәүләт хезмәте күрсәтүгә турыдан-туры бәйле башка чыгымнар.

16. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гомумхуҗалык ихтыяҗларына база норматив чыгымнарга түбәндәгеләр кертелә:

а) коммуналь хезмәтләргә чыгымнар;

б) күчемсез мөлкәт объектларын тотуга чыгымнар (шул исәптән аренда түләүләренә чыгымнар);

в) аеруча кыйммәткә ия күчемле мөлкәт объектларын тотуга чыгымнар;

г) хезмәт стандарты белән билгеләнгән очракларда административ-идарә итү персоналын кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдә турыдан-туры катнашмаган хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү буенча акча күчерүләр белән хезмәт өчен түләүгә чыгымнар;

д) башка гомумхуҗалык ихтыяҗларына чыгымнар.

17. Әлеге Нигезләмәнең 16 нчы пунктындагы «а» – «д» пунктчаларында күрсәтелгән чыгымнарга дәүләт йөкләмәсен үтәү өчен һәм гомумхуҗалык ихтыяҗларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүгә аренда шартнамәсе (финанс арендасы) яки түләүсез файдалану шартнамәсе нигезендә файдаланыла торган учреждение мөлкәтенә (алга таба – дәүләт йөкләмәсен үтәү өчен кирәкле мөлкәт) караган чыгымнар кертелә.

18. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар мәгънәләре гомуми сумма булып, шул исәптән түбәндәге база норматив чыгымнар яктылыгында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана (кирәк булган очракта, чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре нигезләмәләрен формалаштырганда тәгаенләнә):

а) дәүләт хезмәте күрсәтүгә турыдан-туры бәйле чыгымнар;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гомумхуҗалык ихтыяҗларына чыгымнар.

19. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләгәндә кулланыла торган коррекцияләүче коэффициентлар территориаль коррекцияләүче коэффициент һәм тармак коррекцияләүче коэффициенттан тора.

20. Территориаль коррекцияләүче коэффициентка, норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе турындагы расланган нигезләмәләр нигезендә, хезмәт өчен түләүгә акча күчерүләр белән хезмәт өчен түләүгә территориаль коррекцияләүче коэффициент һәм коммуналь хезмәтләргә һәм күчемсез мөлкәтне тотуга территориаль коррекцияләүче коэффициент кертелә.

21. Тармак коррекцияләүче коэффициент тармак үзенчәлекләре күрсәткечләрен исәпкә ала һәм норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе турындагы расланган нигезләмәләр нигезендә билгеләнә.

22. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарның һәм тармак коррекцияләүче коэффициентларның мәгънәләре Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми сайтында билгеләнгән тәртиптә урнаштырылырга тиеш.

23. Эшләр башкаруга норматив чыгымнар дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү күләмен исәпләгәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган тәртиптә билгеләнә.

24. Эш башкаруга норматив чыгымнар тулысынча эшкә яки, дәүләт йөкләмәсендә эш башкару күләме күрсәткечләрен билгеләгән очракта, эш күләме берәмлегенә исәпләнә.

25. Эш башкаруга норматив чыгымнарга шул исәптән түбәндәгеләр кертелә:

а) административ-идарә итү персоналын кертеп, дәүләт эше башкаруга турыдан-туры бәйле хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү буенча акча күчерүләр белән хезмәт өчен түләүгә чыгымнар;

б) нәтиҗәле файдалану вакытын исәпкә алып, эш башкару процессында кулланыла (файдаланыла) торган матди запаслар һәм аеруча кыйммәткә ия күчемле мөлкәт сатып алуга чыгымнар (шул исәптән аренда түләүләренә чыгымнар);

в) эш башкаруга турыдан-туры бәйле башка чыгымнарга тотылган акчалар;

г) коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнар;

д) дәүләт йөкләмәсен үтәү өчен кирәкле күчемсез мөлкәт объектларын тотуга чыгымнар (шул исәптән аренда түләүләренә чыгымнар);

е) аеручы кыйммәткә ия күчемле мөлкәт, дәүләт йөкләмәсен үтәү өчен кирәкле мөлкәт объектларын тотуга чыгымнар;

ж) элемтә хезмәтләре сатып алуга чыгымнар;

з) транспорт хезмәтләре сатып алуга чыгымнар;

и) административ-идарә итү персоналын кертеп, хезмәт өчен түләү буенча акча күчерүләр белән хезмәт өчен түләүгә чыгымнар;

к) башка гомумхуҗалык ихтыяҗларына чыгымнар.

26. Эш башкаруга норматив чыгымнарны билгеләгәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, шулай ук Россия Федерациясе дәүләтара, милли (дәүләт) стандартлары, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, санитария нормалары һәм кагыйдәләре, билгеләнгән өлкәдә эшләр башкару стандартлары, тәртипләре һәм регламентлары белән билгеләнгән, эш башкару өчен файдаланыла торган матди, техник ресурслар һәм хезмәт ресурслары күрсәткечләре кулланыла.

Эшләр башкаруга норматив чыгымнар мәгънәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

27. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү күләменә алар буенча учреждение мөлкәте салым салу объекты дип танылган салымнарны түләүгә чыгымнар кертелә.

Дәүләт бюджет учреждениесе яки автоном учреждение физик һәм юридик затларга, билгеләнгән дәүләт йөкләмәсенә өстәп (социаль яклау өлкәсендә өйгә килеп хезмәт күрсәтү рәвешендә түләүле хезмәтләр күрсәтүдән тыш), түләүле дәүләт хезмәтләре күрсәткән (эшләр башкарган) (алга таба – түләүле эшчәнлек) очракта, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән чыгымнар, хисап финанс елында алынган планлаштырылган керемнәрдән чыгып, дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә субсидиядән һәм түләүле эшчәнлек табышларыннан планлаштырылган керемнәрне үз эченә алган гомуми суммага карата әлеге максатларга, хисап финанс елында Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган

субсидия күләмнәреннән чыгып, дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүнең планлаштырылган күләме чагыштырмасы буларак билгеләнә торган түләүле эшчәнлек коэффициентын (алга таба – түләүле эшчәнлек коэффициенты) кулланып исәпләнә.

28. Дәүләт бюджет учреждениесе яки автоном учреждение түләүле эшчәнлекне аның буенча федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләтү күздә тотылган билгеләнгән дәүләт йөкләмәсе кысаларында гамәлгә ашырса, норматив чыгымнар нигезендә исәпләнгән дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү күләме, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып, аны күрсәтү (башкару) өчен түләтү күздә тотылган дәүләт хезмәте (эш) күләменнән һәм гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган тарафыннан дәүләт йөкләмәсендә билгеләнгән түләү (бәя, тариф) күләменең уртача мәгънәсеннән чыгып, түләүле эшчәнлектән керемнәр күләменә киметелергә тиеш.

29. Әлеге Нигезләмә нигезендә билгеләнә торган норматив чыгымнар чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре нигезләмәләрен формалаштырганда исәпкә алына.

30. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Бюджет учреждениесе яки автоном учреждение тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү дәүләт субсидия бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Дәүләт казна учреждениесе тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү әлеге учреждениенең бюджет сметасы күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

31. Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт бюджет учреждениесенә яки автоном учреждениегә бирелгән субсидия күләмен үзгәртү аны үтәү вакыты дәвамында законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

32. Субсидия дәүләт бюджет учреждениесенең яки автоном учреждениенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган шәхси исәбенә билгеләнгән тәртиптә күчерелә.

33. Дәүләт бюджет учреждениесенә яки автоном учреждениегә финанс елы дәвамында субсидия бирү дәүләт бюджет учреждениеләрен һәм автоном учреждениеләрне гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан дәүләт бюджет учреждениесе яки автоном учреждение белән төзелә торган субсидия бирү тәртибе һәм шартлары турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү якларның хокукларын, вазыйфаларын һәм җаваплылыгын, шул исәптән финанс елы дәвамында субсидия бирү күләмен һәм кабатлану вакытын билгели.

34. Учреждение җиткерелгән дәүләт йөкләмәсен үтәмәгән очракта, дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R = \sum_i N_i \times V_{i1} + \sum_i N_{i2} \times V_{i2} + \sum_w N_w - \sum_i P_i \times V_{i1} + N_{ун},$$

монда:

$N_{i2}$ – ведомстволар исемлегенә кертелгән i дәүләт хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар составындагы дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен гомумхуҗалык ихтыяҗларына чыгымнар;

$V_{i1}$ – дәүләт йөкләмәсе белән билгеләнгән хисап чоры йомгаклары буенча i дәүләт хезмәтенең фактагы күләме;

$V_{i2}$ – дәүләт йөкләмәсе белән билгеләнгән i дәүләт хезмәтенең планлаштырылган күләменең хисап чоры йомгаклары буенча i дәүләт хезмәтенең фактагы күләменнән тайпылышы.

35. Дәүләт бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр, дәүләт казна учреждениеләре тиешенчә дәүләт бюджет учреждениеләрен яки автоном учреждениеләрне гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы органнарга, карамакларында дәүләт казна учреждениеләре булган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләргә дәүләт йөкләмәсендә билгеләнгән таләпләр нигезендә, әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча дәүләт йөкләмәсен үтәү турында хисап кертә.

36. Дәүләт казна учреждениеләре, дәүләт бюджет учреждениеләре яки автоном учреждениеләр тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне тикшерүдә тотуны карамакларында дәүләт казна учреждениеләре булган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр һәм дәүләт бюджет учреждениеләрен яки автоном учреждениеләрне гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы органнар гамәлгә ашыра.